ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

03 мая 2017 г.

**КАРАР**

№ 2748

Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2016 елның 25 мартындагы 1316 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3251 номерлы карары редакциясендә) белән расланган «Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын тормышка ашыра торган белем бирү оешмаларына (балалар бакчаларына) балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» муниципаль хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең (мәктәпкәчә белем бирү бүлеге) урнашу урыны: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Цветочный бульвары, 1А йорт (Яңа шәһәр, 20/07А йорт).

Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең (мәктәпкәчә белем бирү бүлеге) эш графигы: дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр.

Килүчеләрне кабул итү: дүшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга 8.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр.»;

2) пункт 1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенең белешмә телефоннары: 56-12-67, 56-14-74.».

2. Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы В.Х. Харисовка әлеге карарны тиешле мәгълүмат системаларында һәм «Интернет» челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин